*Муниципаль тур*

**РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕ**

**(2018/2019 НЧЫ УКУ ЕЛЫ)**

**4 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты-90 минут**

**I. Тестлардан берәр дөрес җавапны билгеләгез.**

1. Тамыры борын авазына беткән исемнәр рәтен билгеләгез:

а) баланнан, утынлык;

ә) сүзне, баланы;

б) төсле, көчсез;

в) илем, әнием.

2. *«Табигать»* сүзенә туры килгән дөрес аңлатманы күрсәтегез.

а) сүз бары тик саңгырау тартыклардан гына тора;

ә) басым беренче иҗеккә төшә;

б) хәрефләр авазларга караганда күбрәк;

в) сүз ике иҗектән тора.

3. «*Урман кешеләргә тәмле-тәмле җиләкләрен бүләк итә»* җөмләсендә баш кисәкләр рәтен табыгыз:

а) җиләкләрен бүләк итә;

ә) кешеләргә бүләк итә;

б) бүләк итә;

в) урман бүләк итә.

4. Тоташ текст барлыкка килсен өчен, җөмләләр кайсы варианттагы тәртиптә урнашырга тиеш?

1) Ул көн дә  йомырка сала. 2) Ул йомыркаларның ничә икәнен әби үзе дә белми торгандыр әле. 3) Әби ак тавыгын бик ярата, аны төрле тәмле җимнәр белән сыйлый, ә йомыркаларны иләккә җыя бара. 4) Безнең әбинең

ак тавыгы бар. 5) Ул иләктә ак тавыкның йомыркалары бик күп. 6) Бер дә санап бетерерлек түгел. *(А. Алиштан)*

а) 1, 5, 6, 3, 2, 4;

ә) 4, 1, 3, 5, 6, 2;

б) 1, 2, 3, 4, 5, 6;

в) 4, 1, 2, 6, 3, 5.

5. III нче зат берлек сандагы хәзерге заман хикәя фигыль булган җөмләне билгеләгез.

а) Мин тырышып укыйм.

ә) Алар кышын чаңгыда шуалар.

б) Айсылу көн дә әнисенә булыша.

в) Рөстәм кичә китапханәдән кызыклы китап алды.

**II. Текстны укыгыз һәм 6-9 биремнәрне үтәгез.**

[1]Күл буенда тамыр җәйгән биек наратта карт тукран – Тук-тук бабай һән аның Шуктуган исемле оныгы яши. [2]Һәр көн иртән Тук-тук бабай агачларны тукылдатып карый, кайры асларына корт төшмәгәнме, ботакларын зарарлы бөҗәкләр кимермиме дип тикшерә.

[3]Урманда агачлар бик күп, шуңа күрә Тук-тук бабай иртәдән кичкә кадәр ял белми эшли, ә оныгы Шуктуган көне буе уйный, шаяра. [4]Шуктуган ботактан-ботакка оча, күбәләкләр куа, кечкенә кәлтәләрне куркыта. [5]Шулай уйный-сикерә торгач бик эсселәп китсә, күлгә төшеп су коена. [6]Ашыйсы килсә, тизрәк оясына ашыга. [7]Ә анда барысы да күптән әзер: Тук-тук бабасы аңа татлы җиләкләр, симез-симез бөҗәкләр әзерләп куйган була. *(Җ. Тәрҗемановтан)*

1. Түбәндәге сүзләр татарча-русча сүзлектә нинди тәртиптә бирелер? 1 дән 6 га кадәр булган саннарны куегыз. Сүзләрне рус теленә тәрҗемә итегез.

- нарат

- зарарлы

- онык

- кәлтә

- бөҗәк

- җиләкләр

2. Бирелгән сүзләрне таблицага урнаштырыгыз.

*Эшли, тикшерә, карт, яши, коена, биек, ял, шаяра*

| Иҗекләр саны | Авазлар һәм хәрефләр саны туры килә | Авазлар һәм хәрефләр саны туры килми |
|---|---|---|
| сүз бер иҗектән тора | | |
| сүз ике иҗектән тора | | |
| сүз өч иҗектән тора | | |

3. Бирелгән сүзләрне ясалыш ысуллары буенча таблицага языгыз.

| Тамыр сүзләр | Кушма сүзләр | Парлы сүзләр | Ясалма сүзләр |
|---|---|---|---|
| | | | |

Шуктуган, Тук-Тук, татлы, ботактан-ботакка, күбәләкләр, зарарлы, симез-симез, тукран.

4. *«Уйнавын уйна, эшең турында да уйла»* дигән мәкальгә таянып, Шуктуганга киңәшләр бирегез (7 җөмлә).

**III. Бирелгән сүзләрне (бәйлекләрне) нокталар урынына дөрес итеп языгыз.**

Ай яктысы бигрәк якты,
Көн яктысы ... түгел.
Гөлләр ... матурлана
Безнең хәзерге көннәр.
Бакчаларга керүләрем
Матур чәчәкләр ... .

Идел буе ямьле була

Җилфердәгән тал ... .

Бәйлекләр: *өчен, кебек, белән, күк.*

*Муниципаль тур*

**РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕ (2018/2019 НЧЫ УКУ ЕЛЫ)**

**Үткәрү вакыты - 90 минут**

**5 нче сыйныф**

**I. Тиешле сүзләрне куегыз һәм биремнәрне үтәгез.**

... исемнәр бер төрдән булган әйберләрне, күренешләрне атыйлар: *урам, шәһәр, малай*. Бер төрдән булган предметларның берсенә генә бирелә торган исем ... исем була.

Исемнәр ике төрле санда - ... һәм ... булалар. Исемнәрнең күплек төрен ясау өчен, борын авазларына беткән исемнәргә ... һәм ..., ә калган барлык исемнәргә ... һәм ... кушымчалары ялгана.

1. Татар телендә барлык исемнәр дә килеш белән төрләнә. Хәзерге татар әдәби телендә ничә килеш бар? Аларны язып чыгыгыз.

2. *Пароход, фамилия, Биектау, иле, китап, бакча* сүзләрен чыгыш килешенә куеп языгыз.

3. «*Казан – Татарстанның башкаласы»* – дигән җөмләнең баш һәм иярчен кисәкләрен күрсәтегез.

**II**. **Тестлардан берәр дөрес җавапны билгеләгез.**

1. Тамыры саңгырау тартыкка беткән исемнәр рәтен билгеләгез:

а) урманга, өйдән;

ә) ачкычка, тырышлыкны;

б) ноктаны, сердәш;

в) сүзгә, бүлмә.

2. Антоним сүзләр рәтен күрсәтегез:

а) сөенеч, куаныч;

ә) туры, кыек;

б) яңа, ямьле;

в) баллы, татлы.

3. Ясагыч кушымчалар ялганган сүзләр рәтен табыгыз:

а) авылда, сыйныфны;

ә) башлык, күзлек;

б) дәфтәргә, билгеләр;

в) савыт-саба, балалар.

4. Боерык фигыль булган җөмләне билгеләгез:

а) Эшне башлама, башласаң ташлама.

ә) Эш остадан курка.

б) Тырышкан табар, ташка кадак кагар.

в) Чебешне көз көне саныйлар.

5. Парлы тартыкларга башланган сүзләр рәтен күрсәтегез:

а) вакыт, ваза;

ә) нарат, миләш;

б) хәтер, һәйкәл;

в) җиләк, чиләк.

6. *Ул* алмашлыгы юнәлеш килешендә кулланылган җөмләне билгеләгез.

а) Тик бер Кызылтүш кенә курыкмады.

ә) Ул әле коңгыз, әле орлык белән туенды.

б) Октябрь аңа салкын җилләрен өрде.

в) Аның туны да җылы, миләше дә бик тәмле иде шул.

7. Сыйфатлар гына булган рәтне табыгыз:

а) кышлар, җиңеллек;

ә) кып-кызыл, зәңгәрсу;

б) турыпочмак, икенче;

в) урамда, бикләгән.

8. Тартым кушымчасы ялганган сүзләр рәтен билгеләгез:

а) абый, балачак;

ә) өстәлем, апасы;

б) киемнәр, әбиләр;

в) милләт, телләр.

9. Белдерү тексты барлыкка килсен өчен, җөмләләр кайсы варианттагы тәртиптә урнашырга тиеш?

1) Анда язучылар катнашачак. 2) Иртәгә, унбишенче гыйнварда, «Туган тел» түгәрәге утырышы була. 3) Утырыш зур залда кичке сәгать алтыда башланачак. 4) Алар үзләренең әсәрләрен укыячаклар.

а) 2, 3, 1, 4;

ә) 2, 1, 4, 3;

б) 3, 2, 1, 4;

в) 2, 1, 3, 4.

**III. Нәүрүз бәйрәмендә әйтелә торган теләктәге билгеләнгән сүзләр нәрсәне аңлата?**

Нәүрүз әйттек без сезгә,

Хакын бирегез безгә;

Яшегез җитсен йөзгә,

Малыгыз артсын көзгә,

*Нәүрүз Мөбарәкбад*.

*Муниципаль тур*

**РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕ (2018/2019 НЧЫ УКУ ЕЛЫ)**

**6 нчы сыйныф**

**Үткәрү вакыты-120 минут**

**I. Табышмакларның җавапларын табыгыз һәм биремнәрне үтәгез.**

а) Урманнан куркып чыгар, үзе чабар.

ә) Йомры, йомшак сары йомгак
Йөгереп йөри чирәмдә.

б) Кош түгел, оча,
Ябалактан курка,
Чикләвекне ярата,
Сызгырса, урманны
яңгырата.

в) Башы тарак,
Койрыгы урак,
Кычкыртып быргысын,
Уята барысын.

1. Бирелгән табышмаклардан түбәндәге фонетик күренешләргә мисаллар табып языгыз:

Ирен гармониясе күзәтелгән сүзләр:
Борын ассимиляциясе күзәтелгән сүзләр:
[w] ирен-ирен тартык авазы булган сүз:
Ике аваз кушылмасын белдергән хәрефләр булган сүзләр:
Бары тик саңгырау тартыклардан гына торган сүзләр:

2. Табышмаклардан түбәндәге сүз төркемнәренә мисаллар табып языгыз:

Тартымлы исемнәр:
Киләчәк заман хикәя фигыльләр:
Сыйфатлар:

3. Хайваннар яки кошлар турында 3 табышмак уйлап языгыз.

**II. Татар телендә ничә төрле иҗек бар? Һәр төренә 1 әр мисал языгыз.**

**III. Беренче баганада бирелгән тел күренешләренә туры килгән мисалларны икенче баганадан табыгыз.**

| Тел күренеше | Мисал |
|---|---|
| 1. Омонимнар | А. *Эш кайный, поезд чаба* |
| 2. Синонимнар | Ә. *Туп – туп, көзге – көзге* |
| 3. Антонимнар | Б. *Ким – тулы, керү – чыгу* |
| 4. Күчерелмә мәгънәле сүзләр | В. *Яратабыз, сөябез* |

**IV. *“Ата-анаңны тәрбия ит, үзең дә тәрбия күрерсең”* дигән мәкальнең мәгънәсен бәйләнешле 10 җөмлә белән аңлатып языгыз.**

*Муниципаль тур*

**РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ**
**ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН**
**ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕ**
**(2018/2019 НЧЫ УКУ ЕЛЫ)**

**Үткәрү вакыты-180 минут**

**7 нче сыйныф**

**I. Тестлардан берәр дөрес җавапны билгеләгез.**

1. Артыклык дәрәҗәсендәге сыйфат булган җөмләне билгеләгез.

а) Яңа ел – иң борынгы бәйрәмнәрнең берсе.

ә) Россиядә Яңа ел зурлап уздырыла.

б) Яңа ел бәйрәмен бөтен дөньяда беләләр һәм бик теләп үткәрәләр.

в) Кыш бабай һәм Кар кызы балаларга бик күп бүләкләр, күчтәнәчләр өләшәләр.

2. Сызыкча аша языла торган сүзләр рәтен күрсәтегез.

а) җылы(эссе), куе(кызыл)

ә) утыз(ике), ун(җиде)

б) кара(бодай), салават(күпере)

в) аклы(каралы), явым(төшем)

3. Ъ билгесе төшеп калган сүзне билгеләгез.

а) төн..як;

ә) бер..юлы;

б) нәк..;

в) ниһаят.. .

4. Төшем килешендәге исем булган җөмләне табыгыз.

а) Ак колын таудан акрын гына төшә.

ә) Фазыл чикләвекләрен кепкасына бушатты.

б) Югары урын барда түбән утырма.

в) Язын уңмаган, көзен уңмас.

5. Җыю санын күрсәтегез.

а) беренче;

ә) икешәр;

б) өчәү;

в) биш-алты.

6.Раслау җөмләне табыгыз.

а) Малайның гаебе юк иде.

ә) Кунаклар бүген килмиләр.

б) Көн җылы түгел.

в) Караңгы төн үтеп китте.

7. Аергыч дөрес билгеләнгән җөмләне күрсәтегез.

а) **Башта** Рәшитнең аларга бик исе китмәде.

ә) Класста миннән дә **шәп** йөгерүче булмас иде!

б) Актүш **йомшак** тәпие белән көн дә битен юа.

ә) **Колын** яңадан уен башлый.

8. Басымы соңгы иҗеккә төшкән сүзне табыгыз.

а) мондый;

ә) уйламады;

б) укы;

в) китаплар.

**II. Җөмләләрне укыгыз һәм 9-15 биремнәрне үтәгез.**

[1]Татар халкының милли ашлар әзерләү осталыгы бик күптәннән килә. [2]Күп гасырларга сузылган тарих дәвамында милли оригиналь ашлар барлыкка килгән. [3]Татар табынының үзенчәлекле ягын камыр ашлары, барыннан да элек, токмачлы аш тәшкил итә. [4]Халыкның яраткан борынгы ашамлыкларыннан берсе – бәлеш. [5]Аны эченә ит һәм ярма яки бәрәңге салып пешергәннәр. [6]Татар халкы чәйне элек-электән яратып эчкән. [7]Камыр азыклары – кабартма, коймак белән чәй хәзер дә иртәнге ашны алыштыра. [8]Татар ашлары тиз өлгерә торган татлы камырдан әзерләнгән ашамлыкларга бик бай. [9]Һәр туй мәҗлесендә чәкчәк хөрмәтле сыйлардан санала. [10]Чәй белән сыйлау татар халкында кунакчыллыкның бер билгесе булып тора. («Татар халык ашлары» китабыннан)

9. Ирен гармониясе күзәтелгән сүзләрне язып алыгыз.

10. 4-6 нчы җөмләләрдән сыйфат фигыльне язып алыгыз.

11. 7-8 нче җөмләләрдән рәвешләрне язып алыгыз.

12. 9 нчы җөмләнең баш кисәкләрен күрсәтегез.

13. *Сыйлау* сүзенең синонимнарын уйлап языгыз.

14. Түбәндәге сүзләр татарча-русча сүзлектә нинди тәртиптә бирелер? 1 дән 6 га кадәр саннарны куеп, тиешле тәртипне күрсәтегез. Сүзләрне рус теленә тәрҗемә итегез.

_ Милли, _ гасыр, _ табын, _ камыр, _ ярма, _ хөрмәтле, _ кунакчыллык

15. *Әдәпле кунак нинди була?* дигән сорауга 12 җөмлә күләмендә җавап языгыз.

**III. Әлеге шигырьдә *кыткылдый, чыркылдый, бакылдый, каңгылдый, каркылдый* сүзләре кайсы сүз төркеменә карый? Аларның ясалыш төрен билгеләгез.**

Асыл кояш, кил бире,

Кил бире, китмә кире!

Кошлар да көтә сине:

Тавыклар да кыткылдый,

Чыпчыклар да чыркылдый,

Ак үрдәкләр бакылдый,

Ата казлар каңгылдый,

Каргалар да каркылдый...

*Муниципаль тур*

**РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕ**

**(2018/2019 НЧЫ УКУ ЕЛЫ)**

**Үткәрү вакыты-180 минут**

## 8 нче сыйныф

**I. Татарчага тәрҗемә итегез.**

Крокодиловы слезы

Это выражение употребляется в значении «лицемерное покаяние или жалость, притворное сожаление, сострадание». Возникло это выражение из древнего поверья, будто бы крокодил, перед тем как съесть жертву, плачет. Рассказывают также, будто крокодил приманивает к берегу людей, подражая детскому плачу.

Плачут ли на самом деле крокодилы? По утверждению шведских ученых Фанге и Шмидт-Ниотсона, крокодилы и в самом деле плачут. Но не от «избытка чувств», а от избытка солей, скапливающихся у них в организме. Известно, что соль выходит через протоки, расположенные у самых глаз крокодила. *(По Л.Т. Григорян)*

**II. Текстны укып, биремнәрне үтәгез.**

Гаҗәеп иде урман. Тын. Шундый тын, ник бер җан әсәре сизелсен, ник бер шылт иткән тавыш ишетелсен! Әгәр юри генә кычкырсаң, тавыш, калтырана-калтырана яңгырап, әллә кайларга китә дә югала. Шунда ук куе тынлык, таш чумган су өсте шикелле, кире урнаша. Тирә-юньдә бер генә нәрсә дә уянмый, селкенми. Ичмасам, берәр озын койрыклы саескан да сискәнеп, агачлар арасыннан кыеклап очып китми.

Ә яктылык! Әйтерсең, урман өстенә бриллиант тузаны яуган. Бөтен җир: агач ботаклары, ачык урыннар – бар да утта яна. Мамыктай күперенеп, тәңкәләнеп каткан кар өстеннән кояш нурлары кире чәчриләр. Шуңа да һич туры карап булмый. Шундый мул яктылык! *(Ә. Еникидән)*

1. Беренче кызыл юлдан әйтелеше белән язылышы туры килмәгән 4 сүзне табып языгыз.
2. Шушы сүзләрнең транскрипцияләрен языгыз.
3. Икенче кызыл юлдан авазлар саны белән хәрефләр саны туры килмәгән 3 сүзне языгыз.
4. Беренче кызыл юлдан 4 кисәкчәне табып языгыз.

5. Бер тезүче, бер ияртүче теркәгеч кергән җөмләне табып языгыз.

6. Тексттан 8 затланышсыз фигыльне табып языгыз, төрләрен күрсәтегез.

7. 5 җөмлә өстәп, текстны дәвам итеп языгыз.

**III. Билгеле булганча, *тел* сүзенең мәгънәләре бик күп. Шуларның 6-7 сен искә төшереп, җөмләләр төзеп языгыз.**

*Муниципаль тур*

**РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕ**
**(2018/2019 НЧЫ УКУ ЕЛЫ)**

**9 нчы сыйныф**

**Үткәрү вакыты-180 минут**

**I. Татарчага тәрҗемә итегез.**

Красная строка

Когда мы пишем, то прибегаем к красной строке. И в книгах есть красные строки. Но почему строку, с которой начинается каждый абзац, мы называем *красной,* а не белой или синей?

А вот почему. Когда еще не было изобретено книгопечатание, книги переписывались от руки. Перед писцом стояли баночки с тушью двух цветов – черной и красной. Весь текст переписывался черной тушью, а начиная новую страницу, писец менял кисточку, рисовал замысловатый узор, выводил красной краской фигурную первую букву.

В древнерусском языке слово *красный* употреблялось в значении «красивый», например, *красна девица, красное словечко*. *(По Л.Т. Григорян)*

**II. Текстны укып, биремнәрне үтәгез.**

Җиде бабаңны белү шул ук вакытта алардан үрчегән җиде буын нәселне – кардәшләреңне белү дигән сүз. Адәм баласы ялгыз яшәми, аңа шатлыкта да, кайгыда да иптәш, таяныч кирәк. Иң ышынычлысы, әлбәттә – кан кардәшләрең. Кан кардәшләргә, гадәттә, тел, гореф-гадәт, йола-зәвык,

җыр уртаклыгы да хас. Уртаклык, охшашлыклар күп булган саен, бер-береңне аңлау, нәселдәшләрең белән тормыш авырлыкларын җиңү дә җиңеләя. Нык, ишле нәсел язмышның кар-бураннарын, җил-давылларын ансатрак кичә, үз йөзен әйбәтрәк саклый, димәк, сәламәт рухын, ирекле яшәү мөмкинлеген  яхшырак тәэмин итә. Бары шул очракта гына адәм баласы рухи тынычлык, канәгатьлек, рәхәтлекне тоя һәм, сәләтен тулырак ачып, алга таба бара.  *(Т. Әйдидән)*

1. Тексттан тамыр+ясагыч кушымча+модальлек кушымчасы+бәйләгеч кушымча+бәйләгеч кушымча схемасына туры килгән исемне табып языгыз.
2. Шул сүздәге кушымчаларының чикләрен билгеләгез.
3. Аныклагыч булган җөмләне табып языгыз.
4. Шул җөмләдәге тыныш билгесенең куелышын аңлатыгыз.
5. Бирелгән җөмләгә тулы характеристика бирегез.

*Нык, ишле нәсел язмышның кар-бураннарын, җил-давылларын ансатрак кичә, үз йөзен әйбәтрәк саклый, димәк, сәламәт рухын, ирекле яшәү мөмкинлеген  яхшырак тәэмин итә.*

6. Бирелгән җөмләдәге сүзтезмәләрне языгыз.

*Нык, ишле нәсел язмышның кар-бураннарын, җил-давылларын ансатрак кичә, үз йөзен әйбәтрәк саклый, димәк, сәламәт рухын, ирекле яшәү мөмкинлеген  яхшырак тәэмин итә*.

7. Асыл сыйфатлар рәвеш хәле булып килгән җөмләләрне табып языгыз.
8. Шул җөмләләрдәге рәвеш хәлләренең асларына сызыгыз.
9. Үзегезнең кардәш-ыруыгыз турында 5 җөмлә өстәп, дәвам итеп языгыз.

**III. Җирле сөйләмдә кулланылган исемнәрнең әдәби телдәге вариантларын табып языгыз.**

Бәзертдин

Гөлҗийан

Дәкийә

Изел

Җәнипә

Нәпис

Шийап

*Муниципаль тур*

**РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕ (2018/2019 НЧЫ УКУ ЕЛЫ)**

**10 нчы сыйныф**

**Үткәрү вакыты-180 минут**

**I. Татарчага тәрҗемә итегез.**

С первым апреля

Почему люди шутят друг над другом 1 апреля?

Обычай этот очень древний. Некоторые пытались объяснить его тем, что апрель, мол, самый изменчивый и неустойчивый месяц. Очень часто подводит людей погода в апреле. Поэтому первый день месяца отмечается шутливыми проделками.

Однако это объяснение неверно. В южных странах, где апрель – настоящий весенний месяц, тоже издавна существовал такой обычай. У древних индусов днем шуток и затей было 31 марта, в Древнем Риме в те же дни был «праздник глупых».

Из глубокой древности перешел этот обычай и к современным европейским народам. *(По Л.Т. Григорян)*

**II. Текстны укып, биремнәрне үтәгез.**

Республикабызда һәр төбәкнең үзенә генә хас кабатланмас, матур, шигъриятле урыннары бар. Кайда гына булсак та, нинди генә матур урыннарны күреп соклансак та, балачакта тәгәрәшеп үскән тугайларыбыз, бормаланып-бормаланып ага торган елгаларыбыз, аларның тирә-юне, талгын гына итеп канатларын кагып куйган җилдә дерелдәп, тирбәлеп, төсен үзгәртеп тора торган чәчәкле, сазлыклы яр буйлары, төрле-төрле балыкларга бай күл һәм буалар безне һәрвакыт үзенә тарта. Гомер үткән саен, алар

үзәкне өзәрлек итеп, күңел кылларының иң нечкә тойгыларын яңартып, балачагыбызның кире кайтарып ала алмый торган изге хатирәләре булып, күңелебезнең иң ерак почмакларында гомер буе сакланып калалар. Мондый моңлы сагынулар, күңел түребезгә гасырлар дәвамында салына килеп, буыннан буынга, нәселдән нәселгә бирелә барганнар. *(Ф. Гариповадан)*

1. Тексттан алынган сүзләрнең берәр синонимын языгыз.
   *Матур –*
   *Тугайларыбыз –*
   *Талгын –*
   *Хатирәләре –*
2. Икенче җөмләдән басымы беренче иҗеккә төшкән 3 сүзне язып алыгыз.
3. Тексттан алынган җөмләнең төрен билгеләгез.

*Гомер үткән саен, алар үзәкне өзәрлек итеп, күңел кылларының иң нечкә тойгыларын яңартып, балачагыбызның кире кайтарып ала алмый торган изге хатирәләре булып, күңелебезнең иң ерак почмакларында гомер буе сакланып калалар.*

4. Хәбәре фигыль белән белдерелмәгән җөмләне языгыз.
5. Йөкләтү юнәлешендәге фигыльләрне язып алыгыз.
6. Алмашлыкларны табып, төркемчәләрен күрсәтегез.
7. Ахыргы җөмләдәге тыныш билгеләренең куелуларын аңлатыгыз.
8. Республикабызның үзегез күреп белгән берәр урыны турында 5 җөмлә өстәп языгыз.

**III. Җирле сөйләмдә очраган сүзләрнең русча вариантларын языгыз.**

баринҗа

бинек

бичкә

гарбун

кәритә

кенәгә

пичинҗә

тугарок

**РУС ТЕЛЕНДӘ БЕЛЕМ БИРҮ ОЕШМАЛАРЫНЫҢ ТАТАР ТӨРКЕМНӘРЕНДӘ БЕЛЕМ АЛУЧЫ УКУЧЫЛАР ӨЧЕН ТАТАР ТЕЛЕННӘН ОЛИМПИАДА БИРЕМНӘРЕ**

**(2018/2019 НЧЫ УКУ ЕЛЫ)**

**11 нче сыйныф**

**Үткәрү вакыты-180 минут**

**I. Татарчага тәрҗемә итегез.**

Хитрая как лиса

Это выражение из китайской сказки.

«Поймал Тигр Лису, а она, хитрая, повертела пушистым хвостом, морду кверху подняла:

– Не посмеешь меня съесть! Я – властелин леса!

Тигр поглядел на маленькую Лису и не поверил:

– Не может быть!

–Не веришь мне? Так пойдем со мною в лес. Посмотришь, как звери меня боятся.

Согласился Тигр.

Лиса важно шагала впереди, а Тигр – следом. Что тут поднялось! Все звери и птицы, увидев Тигра, бросились в чащу, поглубже забрались в норы, поднялись к облакам.

А Лиса еще выше подняла голову:

– Ну, теперь, ты убедился? Кто меня не боится?

– Да, ты действительно могущественная, – ответил Тигр.

Эта сказка была сложена две с лишним тысячи лет назад.

*(По Л.Т. Григорян)*

**II. Текстны укып, биремнәрне үтәгез.**

“Зыялы” сүзе “интеллигент” сүзеннән шактый аерыла. Эчтәлеге ягыннан да, мәгънә күләмен алганда да. Минем уемча, “зыялы”га интеллигентлыктан тыш күпмедер дәрәҗәдә аристократлык та катнаша.

Революциягә кадәр татарның үз зыялылары булган. Аларның зыялылыкка ирешүендә рус мәдәниятенең, русча тәрбияләнүнең катнашы юк дәрәҗәсендә. Алар шәрык культурасын һәм борынгы болгар, кыпчак-төрки бабаларыбыз калдырган мәдәни вә фәнни мирасны үзләштерү, татар халкының тормыш-көнкүреш, яшәү рәвешен сеңдерү аркасында барлыкка килгәннәр. Кызганычка каршы, утызынчы еллардагы зыялыларны юкка чыгару вакытында, алар бик тә аз калганнар. Шуңа да карамастан, Нәкый Исәнбәт, Бакый Урманче, Гомәр Бәширов, Әмирхан Еники, Хәлил Әбҗәлилов, Фатих Хөсни, Мөнирә Булатова безнең үзебезгә генә хас зыялылыкны саклый алганнар. *(М. Юныстан)*

1. Беренче кызыл юлдан сингармонизмның рәт гармониясенә буйсынмый торган сүзләрне табып языгыз.
2. Икенче кызыл юлдан сингармонизмның ирен гармониясе күзәтелгән сүзләрне табып языгыз.
3. Беренче җөмләдәге рәвешне табып, синонимнарын языгыз.
4. Текстгагы исем фигыльләрне табып языгыз.
5. Тексттан алынган сүзләрне русчага тәрҗемә итеп языгыз: *мәдәниятенең, шәрык, мирасны, тормыш-көнкүреш, яшәү рәвешен.*
6. Җөмләнең төрен билгеләгез: *Алар шәрык культурасын һәм борынгы болгар, кыпчак-төрки бабаларыбыз калдырган мәдәни вә фәнни мирасны үзләштерү, татар халкының тормыш-көнкүреш, яшәү рәвешен сеңдерү аркасында барлыкка килгәннәр.*
7. Ахыргы җөмләдә саналган зыялы шәхесләребезнең берсе турында 5 җөмлә төзеп языгыз.

**III. Бирелгән аутентик текстны әдәби телгә үзгәртеп языгыз.**

Йырлы уйын – парлап бер йегет, бер қыз утыра иде дә дағын торып баса, дағын икенче пар қырына барып, йырның йартысын әйтә, белмәсәләр, урын бирәләр, белсәләр, икенче кешегә китәсең инде. Көлдергеч – кем оста, шул көлдереп әйләнеп чыға, қем қөлми – шул утрып қала, қем қөлә – шуңа җаза бирәләр иде.